# КАРАР

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге составына керүче Олы Кибәче торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

07.11.2024 №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Олы Кибәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Олы Кибәче авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 17 декабрендәге 34 номерлы карары нигезендә, 2025 нче елда Саба муниципаль районының Олы Кибәче авыл җирлеге Олы Кибәче торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Олы Кибәче торак пунктында җәяүлеләр күперен төзү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Олы Кибәче авылында)

дигән сораулар буенча 2024 нче елның 7 нче ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 328 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 170 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның _170_е тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның _0_е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Олы Кибәче авыл җирлегенең Олы Кибәче торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. 2025 нче елда Саба муниципаль районының Олы Кибәче авыл җирлеге Олы Кибәче торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Олы Кибәче торак пунктында җәяүлеләр күперен төзү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Олы Кибәче авылында) дигән сорауларны кабул ителгән дип танырга.

3. Җыен нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/kibiachi адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче:
Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы А.К. Сафин